ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2026 Баулы шәһәре № 6

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Исергәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Исергәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы (алга таба - Проект) проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Проект буенча гавами тыңлаулар инициаторы – Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Гавами тыңлаулар үткәрү срогын 2026 елның 23 гыйнварыннан 2026 елның 2 февраленә кадәр билгеләргә.

4. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен 2026 елның 23 гыйнварында ачарга:

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Исергәп авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Исергәп авылы, Совет урамы, 108А йорт адресы буенча;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы www.bavly.tatarstan.ru сайтында.

4.2. Экспозицияне карау режимы:

- Татарстан Республикасы Баулы районы Исергәп авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Исергәп авылы, Совет ур., 108А йорт;

Эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Гавами тыңлауларда катнашучылар, 2026 елның 23 гыйнварыннан 2026 елның 2 февраленә кадәр, эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га, 13.30 дан 16.00 га кадәр гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

- гавами тыңлаулар оештыручыга язма рәвештә, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 кабинет адресы буенча;

- Bauly.arch@mail.ru электрон почтасы буенча.

6. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә (алга таба – гавами тыңлаулар оештыручы).

7. Гавами тыңлауларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Исергәп авыл җирлеге башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге www.Bavly.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы районы Исергәп авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында, 2026 елның 23 гыйнварыннан 2026 елның 2 февраленә кадәр, эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га, 13.30 дан 16.00 га кадәр, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы www.bavly.tatarstan.ru сайтында оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы И.И. Гозәеров